**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«9» декабрь 2022г. с. Тюлячи № 263

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 196 номерлы «Гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшчәнлекне җайга салу турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Указы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 196 номерлы «Гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшчәнлекне җайга салу турында»карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның исемен түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә карата Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген җайга салу турында»;

- карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең гаиләләрен (гаилә әгъзаларын), шулай ук шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләре гаиләләрен (гаилә әгъзаларына) азат итәргә.

2. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ташламаны, хәрби комиссариатның мәгариф оешмасында укучының гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе, гражданның махсус хәрби операция чорында хезмәт узуы турында башка дәүләт органнарының раслаучы документлары нигезендә бирә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев